2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авылы җирлеге Ерсубайкино авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

18 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Ерсубайкино авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Ерсубайкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: урам яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (ата-аналарыннан, иреннән һәм балаларыннан).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Ерсубайкино авылы, Совет урамы, 11 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгы Е.Г.Николаева